**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"17" ноябрь 2019 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәнгәр авыл жирлегенең Бахтияр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәнгәр авыл җирлеге Бахтияр авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл жирлегенең Бахтияр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәгесорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

а) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту: - Бахтияр авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту һәм кисү.

б) җирле автомобиль юлларында юл эшләре өчен: Бахтияр авылында юлларны төзекләндерү һәм төзү өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәнгәр авыл жирлегенен Бахтияр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Мәнгәр авыл жирлегенен мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл жирлегеБахтияр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Тахавиев Ф.К.